**Тема: “Оясында ни күрсә, очканда шул булыр”.**

**Максат:**

1. Буыннар бәйләнешенең әһәмиятен аңларга ярдәм итү.
2. Гаилә ядкарьләре, традицияләре турында мәгълүмат җыю.
3. Үз гаиләң белән горурлану хисе тәрбияләү.

**Дәреснең көтелгән нәтиҗәсе:**

- “Яхшы тәрбия белән тиңләшә торган бернинди байлык та юк” икәнен хәдиснең асылын аңлау.
- Тәрбияле анага гаиләдә булган таләпләрне үзләштерү.

**Эпиграф:**

- ***“Яхшы тәрбия белән тиңләшә торган бернинди байлык та юк”*** */Хәдис/*

**Дәрес барышы**

**I. Дәреснең темасын ачыклау.**

- Хикәяне тыңлагыз, шуннан чыгып, бүгенге дәреснең темасын үзегез әйтеп бирегез:

**Йөрәк сыкравы**

*Асияне тормыш җиле бер дә какмады. Бердәнбер кыз булгангамы, әти-әнисе артык иркәләп үстерде аны. “Теләгән киемен кисен, теләгәнен ашасын, барасы килгән җиренә барсын”. Әти-әнинең кызны тәрбияләүдәге төп фикерләре шуннан тирәнгә китмәде. Мәктәпне аннан-моннан укып чыккач, Асияне, зур акчалар түгеп, сәүдә институтына укырга керттеләр. Кыскасы, тырыш ата-ана үзләре күрмәгән рәхәтләр, сый-хөрмәт, байлык белән Асияне иркәләделәр. Үз-үзен генә яратучы, теләгәненә үпкәләүләр аша ирешергә өйрәнгән бала тәрбияләделәр алар. Дипломы, матурлыгы булса, тормышта шул җиткән, дип уйладылар.*

*Зур танышлыклар аркылы Асияне яхшы оешмага эшкә урнаштырдылар. Матур, бай кызга күз салучылар да, сүз катучылар да булмады түгел. Ләкин ул сайланды. Аңа күзенә генә карап торучы, аның кураена биергә әзер булган ир-егет кирәк иде. Һәм теләгенә иреште: ул эшләгән оешмага авылдан бер егет килеп урнашты. “Теләгән елан ите ашаган”, – диләр бит. Һәрвакыт җиңүгә гадәтләнгән кыз үзеннән өч яшькә кече егетнең күңелен бик җиңел яулады.*

*Әти-әнисе вафатыннан соң хатын-кызның җылы карашын, тәмле аш-суын тансыклаган егет Асиянең мәхәббәт җепләренә тиз эләкте. Гаилә тормышын бүтәнчәрәк күз алдына китергән Рафаэль хатыны Асиянең эштән җылы ризык, ягымлы йөз белән каршылавына өметләнде. Озакламый үзен ярык тагарак янында калгандай хис итте. Чөнки иркә Асия йортта берни дә эшли белми, эшләргә дә теләми иде. Ләкин иптәш хатыннары белән сәгатьләр буе гайбәт сату, кибетләрдә акча туздыруны бик оста башкарды. Иренең киңәшләрен, өйрәтүләрен ишетергә теләмәде, үзенчә яшәде, акланыр өчен, төрле сәбәпләр уйлап тапты, хәтта ялганга барудан да чирканмады. Рафаэль, аны үзгәртүгә кул селтәп, өйдәге барлык эшне үз җилкәсенә алды. Бик ярата бит ул Асияне, югалтудан курка иде. Балага узганлыгын белгәч, бигрәк тә йомшарды. Өрмәгән җиргә утыртмады, каршы сүз әйтмәде, җылы ризыктан, тәм-томнан өзмәде.*

*Малай көтте Рафаэль. Үзенчә тәрбияләргә, эшкә өйрәтергә хыялланды. Кояшлы май иртәсендә кызы дөньяга аваз салды. Нәни йөрәк җимешен беренче күрүгә яратты Рафаэль...*

*Бала туу белән борчу мәшәкатьләре тагы да артты гына әти кешенең.Кичләрен иптәшләре белән күңел ачулардан туктамады хатыны. Төн уртасында гына тәмәкегә аңкып, хәмердән исереп кайткан чаклары еш булды аның. Түзде ир, барысы хакына да түзде. Менә рәтләнер, менә тормыш тиешле тәртипкә килер дип өметләнде. Асия хәтта кызын карауга, баланың вакытында тамагын туйдыру, режим белән йоклату кебек эшләргә дә игътибар бирмәде. Үзе дә ул күбрәк каты-коты белән аягүрә тамак ялгап кына, ире әзерләгәнне*

*телевизор каршында ашарга гадәтләнде. Гаилә белән табын янында җыелу сирәк күренешкә әйләнде, ашаган ризыкны мактау, әзерләгән кешегә рәхмәт әйтү кебек гамәлләр бу ике хатын-кыз өчен ят иде.*

*"Оясында ни күрсә, очканында шул булыр", – ди халык мәкале. Кызлары Айгөл дә күбрәк әнисе кыланышларын кабатлады. Матур киемнәрне алыштырып кына торды. Салган киемне юу, үтүкләүне белмәде дә. Әтисенә әнисе кебек төксе җаваплар бирү, саубуллашмый-кисәтми өйдән чыгып китү, кара-каршы сүз көрәштерүләргә өйрәнде ул. Асия төн урталарында гына кайткан кызыннан тәмәке исе килүен сизеп, шелтәләп маташкан булды. Әнисенең сүзләре кызны ярсытты гына, әтисенә генә түгел, әнисенә дә тавыш күтәрә башлады. Үзенә каршылык булмаганга гадәтләнгән Асия Айгөлне кычкырып тыңлатырга тырышты. Алар арасында низаглар кабатланып торды.*

*Кызының ялкау, гамьсез булып үсүенә Рафаэльнең йөрәге әрнеде. Көннәрдән беркөнне Айгөлне үзе өйрәтеп карарга булды.*

*– Кызым, син бик акыллы да, матур да. Сине барыбыз да яратабыз, – дип иплән кенә сүз башлады ул. – Акыллы егет очрап, үз тормышыгызны төзерсез. Гаилә тормышында аңлашып яшәү өчен, матурлык кына җитми, кызым. Аз-азлап йорт эшләренә өйрәнсәң, үзеңә рәхәт булыр.*

*– Әни йорт эшләрен эшләми бит әле, барыбер рәхәт яши. Миңа да синең кебек юаш, сүзне тыңлый, күзгә генә карап тора торган, әнием әйтмешли, "мүкләк" очрар әле.*

*Рафаэль бу сүзләрдән телсез калды. Яраткан газизләреннән мондый мөнәсәбәтне көтмәгән иде ул. Ни эшләргә белмәүдән аның күңеле сызланды, тамак төбенә төер тыгылды. Авыр уйлардан арынырга, аны аңламаган кешеләрдән, чарасызлыктан качарга теләп, Рафаэль шау-гөр килеп торган кичке урамга чыгып китте. Машиналар агымына ияреп, ниндидер билгесезлеккә таба ашыга-ашыга атлады да атлады ул... Кинәт барысын басып китәргә теләгәндәй, ниндидер бәрелгән тимер, көчле тормоз тавышлары ишетелде. Машина алдына шау-гөр килеп халык җыелды, юл уртасында әзмәвердәй ир-егет ята иде.*

*Гомеренең уртасына да җитмәгән Рафаэль бөтен борчуларыннан да котылды. Әиренең машинага бәрелеп үлгәнен ишеткән Асия тынсыз калды. Аның өчен утка-суга керергә әзер иде бит Рафаэле. Нишләп аны берүзен калдырып китте? Иреннән башка ничек яшәр? Юлдан язып барган кызын ничек кеше итәр?*

- Димәк, бүгенге дәреснең темасы... (Бәхетсез гаилә турында).
  "Оясында ни күрсә, очканда шул булыр".

**II.Уку мәсьәләсен кую.**

- Төгәлрәк дигәндә, гаиләнең бәхетле, бәхетсез булуы нидән тора, яки "Оясында ни күрсә, очканда шул булыр" дип атала. Сез аның мәгънәсен кешеләр тормышына күчереп аңлатыгыз әле.

- Оя – ул безнең гаиләбез. Безнең киләчәк тормышыбыз гаиләдә нинди тәрбия алуыбызга бәйле. Яхшы гаиләдән начар кешеләр чыкмый.
- Сезгә минем соравым гади генә. Бу гаиләгә характеристика биреп карагыз әле. Ана нинди булган? Ата нинди булган? Сезнең кузаллауга туры киләме?
- Димәк, тәрбиясез хатын (ир) булган гаиләдә бәхетле ир дә, тәрбияле бала да була алмый. Бу ситуация киң таралган. Бүгенге көндә актуаль проблемаларның берсе. Бу гаиләдә инде күп нәрсәне үзгәртеп булмый. Бала тәрбиясез булып үсеп җиткән.
- Ананың хатасы нидә?
- Атаның гаебе бармы- юкмы гаиләнең бәхетсезлектә?
- Фаҗига кайчан һәм кайдан башланган?
- Бу гаиләнең фаҗигасе нидән гыйбарәт?

**III. Уку мәсьәләсен чишү. Төркемнәрдә эшләү.**

**1. Төркемнәрдә эшләү.**

**1нче бирем** ***Уен "Мин башлыйм, син дәвам ит".***

(Мәкальләрне тәрбияче башлый, укучылар дәвам итә).

- Балалар! Хәзер уен уйнап алыйк! Мәкальләрне мин башлыйм- сез дәвам итәрсез.

- Алма агачыннан ерак (төшми).
- Туган бар җирдә (ярдәм бар).
- Тату туганнар таштан (кыйма корганнар).
- Улының ояты – атага, кызның ояты- (анага).
- Атасы барның- (бәхете бар).
- Атасы кем- (углы шул).
- Ата-ананы тыңлаган (адәм булган), тыңламаган - (әрәм булг ан).
- Аз сөйлә, күп (эшлә).
- Оясында ни күрсә, (очканында шул булыр).
- Анасына карап (кызын коч), атасына карап (улын коч).
- Ата- бабасын искә алмаган кеше (игелек күрмәс).

- Кайсы мәкаль хикәянең төп фикерен ачыклый? (Алма агачыннан ерак төшми).

- Бу мәкаль дәреснең эпиграфы буларак тактада язылган.

- Ана газаплар белән баласын тудыра, аны аякка бастыру өчен сәламәтлеген дә, вакытын да кызганмый. Гаиләдә ананы изгеләштерү аның баласының бөтен язмышы, шәхес булып формалашуы, олы тормыш юлында үз кыйбыласын таба алырлык булып үсүе өчен җаваплылык тоюы, баласы-йөрәк парәсе өчен һәрчак җан атуы, аның бәхете хакына бөтен авырлыкларга барырга әзер торуы белән аңлатыла.

- Ата-ана-бала өчен иң якын кеше, иң зур авторитет. Алар аша баланың тормышка карашы, мөнәсәбәте һәм ихтирамы тәрбияләнә. Тәртипле, тату гаиләдә балалар да сабыр холыклы, әдәпле, ихтирамлы булып үсә, чөнки алар иң якын ике кешенең үз ара ихтирамын көн саен, минут саен күреп үсә. Халыкта тагы да шундый әйтемнәр бар: Атаны күреп, ул үсәр, инәне күреп, кыз үсәр. Бу хак сүзләр. Оясында ни күрсә, очканда да шул булыр.

- Гаиләдә атаның да урынын югары бәяле. Әти кешенең сабырлыгы, һәр сүзен уйлап сөйләшүе, җаваплы, кешеләрә итагатьле булуы, иҗтимагый активлыгы игьтибарга лаек. Ата кеше гаиләне яклаучы, туендырычы, яшәү шартларын булдыручы һәм гаилә намусын саклаучы кеше. Ата кешенең күп вакыты йорттан читтә - хезмәттә үтә. Бер үк вакытта ата – аек акыл иясе дә. Ул булмаса, тормышның рәте китә.

- Безнең халык ул өйләндергәндә яки кызын кияүгә биргәндә, булачак кияү яки киленнең нәселенә, ата – аналарның нинди сыйфатларга ия булуына нык игътибар иткән. Шуңа күрә мәкальләрдә дә "Алма агачыннан ерак төшми", "Оясында ни булса, очканында шул булыр" дип әйтелә. Кешеләрне хөрмәт итү, туган – үскән җиргә, илгә, халкыңа мәхәббәт ата белән ананы яратудан башлана. Үрнәк гаиләләрдә өлкән буын вәкилләренең урыны түрдә.

**2нче бирем** ***Ситуациягә бәя бирү.***

- Хәзер сезгә гыйбрәтле өзек тәкъдим итәм. Тыңлагач, хикәягә исем кушарсыз. "Кыз үскән гаилә турында нәрсә әйтә аласыз?"- дигән сорауга җавап әзерли торыгыз.

**-** *Көзнең бик матур бер көне. Мәктәпнең ишегалдына башлангыч мәктәбе укучылыры саф һава суларга чыкканнар, төркемнәргә бүленеп уйныйлар. Кинәт бер кыз, үзеннән кыскарак буйлы бер малайны кыйный башлады. Яннарына йөгереп бардым.*

*– Катя, ник кыйныйсың аны, – дим.*
*– Он сегодня опять пьяный пришёл. Сколько можно? – ди бу.*
*– Сез ничек уйныйсыз соң, – дим, шаккатып. – Бу нинди уен?*
*– Мы играем в семью. Он – мой муж. А это наши дети.*
*Имәнеп киттем, гәҗәпләндем. Фикерләремне җыярга да өлгермәдем, теге кыз, уенын дәвам итеп, «иренә» каты гына итеп кычкырды:*
*– Вон, твой ребёнок орёт. Успокой!*
- Хикәягә сез кушкан исемләрне тыңлап карыйк. (Тәртипсез гаилә. Тәрбиясез кыз).
- Кайсы мәкальләр хикәянең төп фикерен испатлый? (Оясында ни күрсә, очканында шул булыр).
- Хикәяне ахыры болай булган:

*Бу кызны бик кызгандым мин. Менәниләр күрә икән бит ул өендә. Уенны тизрәк туктату ягын карадым. Ирексездән «оясында ни күрсә, очканда шуны кабатлый» дигән халык мәкале искә төште. Өс-башы да матур, җитеш күренә үзе, тик тәрбия ягы үзен бик нык сиздерә.*
*– Андый ямьсез сүзләрне әйтергә ярамый бит. Кем шулай сөйләшә, Катя? –дим.*
*– Мама так папу ругает.*

**3нче бирем *“Алдагы риваятьтән нинди гыйбрәтләр алып була?”- дигән сорауга җавап бирү.***

- Кыз үскән гаилә турында нәрсә әйтә аласыз?/җаваплар/
- Бу риваяттән нинди гыйбрәтләр алып була (нәтиҗә ясарга)?
- Балалар – гаиләнең көзгесе. Бу күңелсез күренеш «гаилә тәрбиясе» нәтиҗәсе турында тагын бер тапкыр уйланырга мәҗбүр итә. Әлеге кешеләрнең ата һәм ана буларак гаиләдәге роле ни дәрәҗәдә икән дигән уй туды. Әти кеше – улы, әни кеше кызы өчен өлге булырга тиеш. Теге яки бу адымны ясар алдыннан бала: «Әти нәрсә дияр. Әни ни әйтер», – дип уйлана белергә тиеш.

**4нче бирем *Үгет- нәсыйхәтләр.***

- Ризаэддин Фәхреддин гаилә тәрбиясе турында болай дигән:

- Алтыннан бәһале, оҗмах нигъмәтләреннән кадерле булган нәрсә – тәрбияле баладыр
- Тәрбияле бала булырга һәр баланың кулыннннан килер һәм көче җитәр.
- Ата- анагыздан соң иң якын кешеләр- бертуганнарыгыздыр.
- Үзегездән олырак туганнарыгызны ата- анагыз кебек хисап итегез, аларга тавыш күтәрмәгез, алар белән низаглашмагыз (ызгышмагыз), сүзләренә каршы әйтмәгез.
- Кечкенә туганнарыгызга шәфкатьле булыгыз, аларны рәнҗетмәгез, аларга кычкырмагыз.
- Туганнарыгызның гөнах, ярамаган эшләрен күрсәгез, йомшаклык белән генә: “Бу эш гаептер- аларны эшләмәгез!”- дип исләренә төшерегез.
- Туганнарыгызны ата- анагызга яманлап сөйләмәгез. Телегезне адәм яманлауга гадәтләндермәгез.
- Үзләре әйткәнне көтмичә, туганнарыгызның һәр изге эшләрендә ярдәмче булыгыз, кулыгыздан килгән изгелекләрне кылуда үзегезне кызганмагыз.
- Туганнарыгызның серләрен саклагыз, аларга шатлыклы хәбәрләр китерүче булыгыз.
- Өй эчендә булган серләрне һичкемгә сөйләмәгез.

**5нче бирем** ***Танылган шәхесләргә сүз бирәбез:***

- *Гаилә тормышында иң әхәмиятле нәрсә – сабырлык (рус язучысы Чернышевский Н. Г.)*
- *Балагызны бәхетсез итәсегез килсә, аның һәрбер теләгәнен үтәгез. Башта ул кулдагы сәгәтьне, аннары- һавадагы кошны, аннары- күктәге йолдызны, аннары- күргән бер нәрсәне сорыячак. Сез Аллаһы Тәгалә түгел- аны ничек канәгатьләндерерсез? (француз язучысы Руссо Ж.)*

- Әти-әниләр балаларына бәхетле балачак телиләр. Тик бәхетле балачак дигәнне ничек аңларга? Авырлыкта үскән, дөнья йөген үз җилкәсенә салган кешенең балачагы булмый, диләр. Ләкин гел бәйрәм, күңел ачу рәвешендә узган балачакны бәхетле дип санап буламы? Гамьсез рәхәтлектә үткән тормыш бушка узган булмыймы?

- Ата-ана мәхәббәте баланы киң күңелле, игелекле, ачык йөзле итә. Шушы мәхәббәт җылысы анда намуслылык, йомшак күңеллелек тәрбияли. Ләкин баланы яратуда чама белергә кирәк. Югыйсә, үзенең ихтыяҗларын канәгатьләндерүдән баш тарта алмый торган кеше үсәргә мөмкин.

**2. Гаиләдә бер- беребез каршында булган бурычларыбызны ачыклау.**

- Гаиләбездә бер- беребез каршында булган бурычларыбызны карап үтик. /Укучылар җавабы/
- Сезнең җавапларыгызны безнең фикерләр белән чагыштырыйк:

  - Хөрмәт йөзеннән үзебездән олыракларга: әти- әниләргә, әби- бабайларга, апа- абыйларга- хәерле эшләрдә буйсынырга, ә кечкенәләргә- ярдәм итәргә .
  - Бер- беребезне яратырга, башкаларның теләк- тәләпләрен истә тотарга, аларга изгелек кылырга.
  - Хәр кеше гаиләсендә булган вазыйфасын бик яхшы башкарырга.
  - Бар кешегә сабыр булырга, башкаларның кимчеләкләрен йомшак итеп күрсәтергә, үзебезнекен тизрәк бөтерергә.
  - Гаиләнең көче- бердәмлектә, татулыгы- сабырлыкта икәнең онытмаска.

- Милләтнең көче, яшәү егәре аның тамырларында. Тамыры нык, таза, тирәндә таралып яткан имән агачына халкыбыз юкка гына йөзьяшәр дигән исем кушмаган. Ә милләтнең тамырларын гаиләләр, ырулар тәшкил итә.Татарлар элек-электән гаилә җанлы булганнар. Аңа күз карасына караган кебек караганнар. Ыруггагы ятим балаларны да читкә җибәрмәгәннәр,үзләре тәрбияләгәннәр. Бөтенлекне, тигезлекне, туганлыкны, шулар аша гореф-гадәтләребезне, милли асылыбызны гасырлар буе әнә шулай саклаганнар. Башына төшкән күп авырлыкларга карамастан, татар халкы дөньяда үзенә лаек урынны биләп тора икән, беренче чиратта, без тамырларыбызга бурычлы.

**3. Тәрбияле ана кодексы.**

- Гаилә – гадел, акыллы, ихтирамга лаек әти-әни дигән сүзләрдән төзелгән сүз. Гаиләнең ныклы, тотрыклы булуы бу төшенчәләрнең камиллегенә бәйле. Гаилә –баланың төп тәрбиячесе, ул шуның өчен төзелә дә. Бала тирә-якны танып белергә иң элек гаилә аша өйрәнә. Гаилә аша урамга, олы дөньяга чыга. «Оясында ни күрсә, очканында шул булыр» дигән мәкаль дә шуннан килә.

- Гомер буе халкыбыз яшәешендә хатын-кызларыбыз үзләренең гүзәл сыйфатлары белән милләтнең горурлыгы гына түгел, терәге-таянычы.Татар халкының милли азатлык өчен көрәш тарихын гына алыйк: халык хәтерендә ватан сагына баскан ир-егетләребез һәм меңнәрчә туташ, ханымнарыбызның язмышы саклана. Риваятьләрдә яшәүче Алтынчәч, Бөек Биләр җирендә актык тамчы каннарына кадәр көрәшеп, дошманга бирелергә теләмичә соңгы сәгатьләрендә кошка әйләнгән кызлар образы... Казан ханлыгының соңгы

патшабикәсе - азатлык өчен көрәшүчеләрнең байрагына әверелгән, чынбарлыктан риваятьләргә күчкән мәшһүр - Сөембикә... Кайсы гына гасырда яшәсәләр дә, алар татар хатын-кызларына хас сыйфатларны югалтмаган. Акыллы, тыйнак, белемле, уңган бу асыл затлар – халкыбызның йөз аклыгы.
- Вакыт кысанлыгын искә алып, сезгә әзер "**Тәрбияле ана кодексы"** тәкъдим итәм.

- Тәрбияле ана, балаларына яхшы тәрбия бирер, аларны саклар өчен, җаны вә тәне белән тырышыр.
- Дөньяга туган сәгатеннән бала тәрбиягә мохтаҗ.
- Тәрбияле ана баласын чиста йөртер, көндәлек режимын саклар.
- Үзе тапкан баласын ана үзе тәрбияләр.
- Тәрбияле ана үзен баласына гайрәтле һәм шәфкатьле итеп танытыр.
- Тәрбияле ана өлкәннәр алдында эшләргә ярамаган эшләрне эшләмәс, сөйләргә ярамаган сүзләрне сөйләмәс.
- Тәрбияле ана баланың ялган сөйләргә өйрәнүеннән, хәйләгә сәбәп булырдай нәрсәләрне эшләвеннән бик сакланыр.
- Тәрбияле ана үзенең киенүе, үз-үзен тотышы, аралашу әдәбе белән балаларына һәрвакыт үрнәк булып торыр.
- Тәрбияле ана үзенең баласына җикереп кычкырмас, беркайчан да сукмас.
- Тәрбияле аналар аталарын балаларга иң хөрмәтле кеше итеп күрсәтерләр, иң зур, иң гайрәтле кеше итеп танытырлар.
- Балаларының күңел биреп укуларын тәрбияле аналар камиллек дип санарлар.
- Тәрбияле ана мәктәптән кайткан баласының дәресләрен сорашыр, укуга мәхәббәт уятыр.
- Тәрбияле аналар кыз балаларын йорт һәм кул эшләренә өйрәтерләр.
- Тәрбияле аналар үзләренең кызларын сафлыкка, җыйнаклыкка гадәтләндерерләр, кыз балада бара торган физиологик үзгәрешләрне җайлап аңлатырлар.
- Тәрбияле аналар явыз иптәшләр белән юлдаш булуның ярамаганлыгын, дусларының яхшы күңелле булырга тиеш икәнлеген аңлатыр.

**4. Хәдисләр.**

- Мөхәммәд Пәйгамбәрнең хәдисләрен укып, алар турында үз фикерләрегезне әйтегез. Мөхәммәд Пәйгамбәр (с.г.с) әйтә:

- ***"Ризыгы киң булуын һәм гомеренең озын булуын теләгән кеше туганнары белән элемтә өзмәсен".***
- ***"Кечкенәләребезгә рәхим-шәфкатьле булмаган кеше безнең арадан түгел".***
- ***"Ата- аналарын риза кылучы балалардан Алла Тәгалә дә риза булыр".***
- ***"Яхшы тәрбия белән тиңләшә торган бернинди байлык та юк".***

**5. Эпиграф белән эш.**

- ***"Яхшы тәрбия белән тиңләшә торган бернинди байлык та юк".***

- Бу сүзләрне дәреснең эпиграфы. Сез аларны ничек аңлыйсыз? /Фикерләшү/

***6.* Изге Коръән китабыннан**.
- Изге Коръән китабында ата- аналар турында болай дип язылган:

- ***"Әгәр аларның (ата- аналарның) берәрсе яки икесе дә синең яныңда картлыкка ирешсәләр, син аларга "уф" дип тә әйтә күрмә, аларга кычкырма, ә яхшы, мөләем сүзләр генә сөйлә"*** (Исра- 23, 24).

- Бүген безгә яңабаштан туарга, күңелләребезне чистартырга кирәк. Ә бит татар гаиләсендәге тәрбия гомер-гомергә үзенең бөтенлеге һәм эзлеклелеге белән аерылып торган. Ана сөте белән сеңгән миһербанлык, җылылык, бишек җырларыннан күчкән моң һәм аһәң, әби-бабайларның тылсымлы әкиятләре һәм, ниһаять, гаилә учагында ныгытылган хезмәт сөючәнлек - болар барысы да милли тәрбиянең какшамас нигезләре. Физик яктан көчле, сәламәт милләт кенә киләчәккә ышаныч белән карый ала.

**VI. Рефлексия (Йомгаклау).**

**-** Дәреснең темасын искә тешерегез.

- “Оясында ни күрсә, очканда шул булыр”.

- Бу темага карата нинди гыйбрәтләр алдыгыз? *("Ризыгы киң булуын һәм гомеренең озын булуын теләгән кеше туганнары белән элемтә өзмәсен”).*

- Бәхетле гаиләдә туганнар бер- берсен... дигән җөмләне дәвам итегез.

- Үзегез өчен нинди нәтиҗә ясадыгыз?*(”Гаиләнең көче- бердәмлектә, татулыгы- сабырлыкта”).*

**VII. Өйгә эш:**

- Өй эшен вариантлап бирәбез:

1. “Гаиләнең бәхете нидән тора?” дигән темага җавап әзерләп килергә.
2. “Безнең күршеләрдә, туганнарыбызда- үрнәк гаилә” дигән темага җавап әзерләп килергә.